Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №V-3**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 03 декабре

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 41 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 45 маддәләре нигезендә Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турындагы кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) яңа редакциядә расларга.

2. Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2011 елның 18 августындагы IX-2 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәне 2020 елның 31 декабреннән үз көчен югалткан дип танырга.

3. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгына Нигезләмәне Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча № 18 районара инспекциясендә законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны башкару буенча вәкаләт бирергә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 03 декабрендәге V-3 номерлы карары белән расланды

**“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Бүлек) Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә мәдәният, сәнгать, мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы, саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы органы булып тора, һәм шулай ук федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә.

Бүлекнең оештыру-хокукый рәвеше – муниципаль казна учреждение.

1.2. Бүлекнең рус телендәге тулы аталышы – Муниципальное казенное учреждение «Отдел социально-культурной сферы Исполнительного комитета Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан».

Рус телендәге кыскартылган аталышы – МКУ «Отдел социально-культурной сферы».

1.3.Бүлекнең татар телендәге тулы аталышы – Балык бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе.

Татар телендәге кыскартылган аталышы – “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе.

1.4. Бүлекне гамәлгә куючы һәм Бүлеккә беркетелгән мөлкәт хуҗасы – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль район). Гамәлгә куючы функцияләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы гамәлгә ашыра, милек хуҗасы функцияләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы башкара.

1.5. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары (күрсәтмәләре), Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыкларына

(күрсәтмәләренә), муниципаль район җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.6. Бүлек юридик зат булып тора, үз исеменнән мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокукларны сатып ала һәм гамәлгә ашыра, вазыйфаларын үти, судларда дәгъвачы, җавап бирүче һәм өченче зат була ала, муниципаль район гербы сурәтләнгән һәм үз аталышы булган мөһер һәм бланкка, үз эшчәнлеге өчен кирәкле булган бүтән мөһерләргә, штампларга, бланкларга, законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган тиешле бюджет һәм башка счетларга ия.

1.7. Бүлек эшчәнлеген финанслау әлеге максатларга бүлеп бирелгән ассигнованиеләр чикләрендә, шулай ук федераль законнар нигезендә муниципаль районга бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен республика бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән муниципаль район бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

1.8. Бүлекнең ведомство буйсынуындагы учреждениеләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Район мәдәният йорты” муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Үзәкләштерелгән китапханә системасы” муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесе;

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы киноучреждениесе” муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Ф.Әхмәдиев исемендәге балалар сәнгать мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе.

Муниципаль районның муниципаль бюджет мәдәният учреждениеләренә бухгалтерлык хезмәте күрсәтү бүлек структурасына керүче финанс-хуҗалык бүлеге аша башкарыла.

1.9. Бүлек структурасына гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә куела торган муниципаль учреждениеләр мөстәкыйль бүлекчәләр сыйфатында керә ала.

1.10. Бүлек аның компетенциясендә билгеләнгән чикләрдә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә әлеге Нигезләмә нигезендә эшчәнлек төрләре буенча оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

1.11. Учреждениенең урнашу урыны (юридик адресы): 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48а йорт.

## 2. Бүлекнең бурычлары

Бүлекнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

2.1. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга, муниципаль районда гражданнарның иҗат ирегенә конституцион хокукларын тормышка ашыру, мәдәни тормышта катнашу һәм мәдәният учреждениеләреннән файдалану, мәдәни кыйммәтләрдән файдалану өчен кирәкле шартлар тудыруга юнәлдерелгән дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итү;

2.2. Мәдәни мирас объектларын саклау, муниципаль район карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә, шулай ук тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә федераль законнарга ярашлы рәвештә дәүләт мәнфәгатьләрендә законнарда билгеләнгән тәртиптә муниципаль район территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларын саклап калуны, алардан файдалануны һәм популярлаштыруны тәэмин итү;

2.3. Россия Федерациясе халыкларына аларның этномәдәни үзенчәлеген саклап калуда һәм мәдәниятне үстерүдә, милләтара мәдәни элемтәләрне ныгытуда, Россия Федерациясе субъектларында һәм чит илләрдә милли-мәдәни автономияләр һәм аларның территориаль органнары, башка оешмалар белән үзара бәйләнештә торуда булышлык итү;

2.4. Муниципаль район составындагы муниципаль берәмлекләргә ял итү өлкәсен үстерүдә, халыкның төрле катламының мәдәни-ял итү эшчәнлеген төрлеләндерүне тәэмин итүдә булышлык күрсәтү;

2.5. Мәдәният өлкәсендәге эшчәнлекнең аерым төрләрен, шул исәптән профессиональ сәнгать, кинематография, фотография, музей һәм китапханә эше, декоратив-гамәли, монументаль сәнгать һәм халык иҗаты, мәдәни-танып белү туризмы, мәдәни мирас, мәдәният өлкәсендә мәгариф һәм фәнне үстерүдә максатларны һәм өстенлекләрне билгеләү.

### 3. Бүлекнең функцияләре

3.1. Бүлек түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

мәдәният өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, муниципаль район милкендәге китапханәләрнең халыкка хезмәт күрсәтүе белән идарә итү;

музейларга, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә, халыкның сәнгати һөнәрләренә (кәсепләренә) ярдәм итү;

билгеләнгән тәртиптә мәдәни мирас объектларын саклау, алардан файдалану һәм популярлаштыру, җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклауны тәэмин итү;

бирелгән вәкаләтләр чикләрендә республика бюджетыннан субвенцияләр хисабына республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын саклау.

3.2.Бүлек түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

муниципаль район территориясендә мәдәният өлкәсен үстерү тенденцияләрен комплекслы анализлау һәм фаразлауны, мәдәни эшчәнлекнең аерым төрләрен үстерүнең максатларын һәм өстенлекләрен нигезләүне үткәрә;

муниципаль районның икътисади һәм социаль үсеш программаларын тормышка ашыруны тәэмин итүдә катнаша;

максатчан программаларны эшләүдә һәм тормышка ашыруны тәэмин итүдә катнаша;

тармакка ярдәм итү чараларын тормышка ашыра, шулай ук тиешле финанс елына муниципаль район бюджетында каралган средстволар чикләрендә сәнгать әсәрләрен булдыру эшләрен финанслауны гамәлгә ашыра;

дәүләт социаль стандартлары кысаларында халыкка мәдәни хезмәт күрсәтүгә, муниципаль ихтыяҗлар өчен продукция җибәрүгә муниципаль заказны

формалаштыруда катнаша,

федераль законнар нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр (шул исәптән сәнгать әсәрләрен булдыру һәм сатып алу) белән тәэмин итүгә муниципаль контрактлар төзи;

муниципаль район бюджеты акчалары хисабына муниципаль учреждениеләрнең төп средстволарына капиталь кертемнәргә гомуми ихтыяҗ формалаштыруда катнаша;

билгеләнгән тәртиптә Бүлек карамагындагы муниципаль учреждениеләрнең максатларына (шул максатларда алар төзелгән) ирешү өчен аларның коммерция проектларын һәм башка эшкуарлык инициативаларын тормышка ашыруга ярдәм итүне гамәлгә ашыра;

билгеләнгән өлкәдә муниципаль район эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләүнең тиешле өлкәдә индикаторлары күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итә;

мәдәният өлкәсендә муниципаль районда икътисади үзгәртеп корулар юнәлешләрен эшли;

тармакның матди-техник базасын ныгытуга һәм үстерүгә бүлеп бирелгән бюджет һәм бюджеттан тыш акчалардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә;

Бүлек карамагындагы муниципаль учреждениеләрне финанслауны тәэмин итә;

мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүгә ярдәм итә;

профессиональ сәнгатьнең барлык төрләрен һәм жанрларын үстерүгә, күренекле татар һәм дөнья эшлеклеләренең иҗади мирасын саклап калуга булышлык итә;

гамәлдәге законнар нигезендә театр-тамаша учреждениеләрен төзи (булдыра), аларга ярдәм итә һәм үстерә;

талантлы яшьләргә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләренә адреслы ярдәм күрсәтү механизмнарын формалаштыра;

Татарстан Республикасында һәм аннан читтә гастрольләр һәм күргәзмә эшчәнлегенә үзидарәлек ярдәме күрсәтүне, төбәкара дәрәҗәдә иҗат коллективлары, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, мәдәният, сәнгать һәм кинематографиянең мәгариф һәм фәнни учреждениеләре арасында элемтәләр урнаштыруны һәм элемтәләрне үстерүне гамәлгә ашыра;

муниципаль районның китапханә эшен, халык иҗатын, мәдәни-ял итү өлкәсен үстерүдә максатларны һәм өстенлекләрне тәгаенли;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм муниципаль район музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә карата үзидарәлек контролен гамәлгә ашыра;

муниципаль музейлар булдыру һәм аларга ярдәм итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт керемена әверелгән мәдәни кыйммәтләрне билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт музее, архив һәм китапханә фондларына тапшырны гамәлгә ашыра;

халык иҗатын саклап калуга һәм үстерүгә, халыкның мәдәни-ял эшчәнлеге төрлелеген тәэмин итүгә булышлык күрсәтә;

халык сәнгать һөнәрчелеген (кәсәбәчелеген) үстерү буенча программа

чаралары эшли һәм тормышка ашыра;

муниципаль районда яшәүче халыкларның милли мәдәниятләрен үстерүгә ярдәм итә;

Бүлек вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр буенча милли-мәдәни автономияләргә, иҗат берлекләренә, башка җәмәгать оешмаларына методик, оештыру һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтә;

милләтара һәм төбәкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә мәдәни хезмәттәшлеккә нигезләнгән дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга сала торган закон һәм башка норматив хокукый актларны, шул исәптән хезмәт өчен түләү өлешендә, мәдәният өлкәсендә тормышка ашыруны тәэмин итә;

ведомство буйсынуындагы мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тота. Бүлек ведомство карамагындагы учреждениеләр эшчәнлегенә тыкшынуны гамәлгә ашырырга түбәндәге өлештә (очракларда) хаклы түгел:

- репертуар һәм сәнгать сәясәтен формалаштыруда;
- китапханә фондларын туплауда;
- иҗади ниятнең сәнгати чагылышының эстетик юнәлешләрен, иҗат актын гамәлгә ашыру урынын һәм вакытын ирекле сайлап алуда, законнарда каралган очраклардан гайре;
- кадрлар мәсьәләләрен хәл итүдә (ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен билгеләп куюдан һәм вазыйфаларыннан азат итүдән гайре). Ведомство буйсынуындагы барлык учреждениеләр Бүлекнең үзәкләштерелгән бухгалтериясе аша финанслана һәм аның алдында хисап тота.

мәдәният өлкәсен кадрлар белән тәэмин итүнең комплекслы программаларын эшли һәм тормышка ашыра, кадрларны әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыра;

тармак хезмәткәрләренә һәм мәдәният эшлеклеләренә социаль ярдәм күрсәтү һәм хокукый яклау чараларын гамәлгә ашыра, аларны дәүләт һәм муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турында үтенечнамә бирә (юллый):

мәдәният өлкәсендә өзлексез белем бирүне үстерүнең һәм мәдәният учреждениеләре өчен тармакны кадрлар белән тәэмин итүнең, тармактагы хезмәт базары ихтыяҗларыннан чыгып, төп юнәлешләрен билгели;

җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын, ачыкланган мәдәни мирас объектларын һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын муниципаль саклауны гамәлгә ашыра (Татарстан Республикасының вәкаләтле органы йөкләмәсе (кушуы) буенча);

мәдәни мирас объектларын саклап калуга, саклауга, алардан файдалануга һәм аларны популярлаштыруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, шул исәптән: мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәүне;

региональ (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының саклау йөкләмәләре һәм региональ (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларыннан файдаланучылар һәм милекчеләр белән саклау йөкләмәләрен төзү тәртибе шартларын үтәү, шулай ук күрсәтелгән саклау шартнамәләренең

шартларын үтәүне; мәдәни мирас объектларының торышын, мәдәни мирас объектларының торышына тикшерү үткәрүне;

муниципаль берәмлек милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру чараларын гамәлгә ашыра;

төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына мәгълүмати өсьязмалар һәм тамгаланышлар урнаштыруны килештерә;

җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштырганда саклык йөкләмәләре шартларын үтәүгә, шулай ук күрсәтелгән саклау йөкләмәләре шартларын үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

документлар әзерләүне оештыра һәм аларны федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә мәдәни мирас объектларын реестрга кертү турында карар кабул итү өчен тапшыра;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән субвенцияләрне тоту турында хисаплылыкны билгеләнгән форма буенча, шулай ук тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның тулы һәм сыйфатлы булуын тикшереп тору һәм күзәтү өчен кирәкле башка документлар һәм мәгълүматны республика башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына үзвакытында тапшыруны тәэмин итә;

мәгълүмати ярдәм күрсәтә, шулай ук җирле үзидарә органнарына, мәдәният өлкәсе учреждениеләренә, иҗат әһелләренә законнар куллану мәсьәләләрендә ярдәм итә;

Бүлек үз эшчәнлеген республика дәүләт һәм башкарма хакимият органнары белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашыра, республика бюджетыннан булган субсидияләрне, социаль чыгымнарны финанслашуның бүтән средстволарын җирле бюджетлар тарафыннан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары турында республика башкарма хакимият органнары белән килешүләр әзерләүне һәм төзүне тәэмин итә.

## 4. Бүлекнең хокуклары һәм бурычлары

4.1. Бүлек хокуклы:

4.1.1. федераль һәм республика башкарма хакимият органнарында муниципаль район Советы, район Башкарма комитеты йөкләмәсе буенча үз вәкилләренең киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашуын тәэмин итәргә;

4.1.2. үз компетенциясе чикләрендә боерык рәвешендә норматив хокукый актлар чыгарырга, Бүлек карамагындагы барлык оешмалар өчен үтәү мәҗбүри булган кагыйдәләрне, нигезләмәләрне, регламентларны, инструкцияләрне, методик документларны расларга;

4.1.3. үз хокукларын яклау максатларында, шулай ук Бүлек вәкаләтләре чикләрендә мәдәни мирас объектларын саклау, саклап калу, алардан файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендә законнарны бозуларны булдырмау максатыннан суд һәм хокук саклау органнарына законнарда билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итәргә;

4.1.4. законнарда каралган тәртиптә муниципаль район бюджеты акчалары,

субвенцияләр рәвешендә бүленә торган республика бюджеты акчалары белән үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән, максатчан программалар, муниципаль актлар белән билгеләнә торган юнәлешләр буенча эш итәргә;

4.1.5. бүлеп бирелә торган акчалар чикләрендә грантлар, стипендияләрне гамәлгә куярга;

4.1.6. мәдәният өлкәсе муниципаль учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган муниципаль мөлкәтне исәпкә алуны, аның сакланышын тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

4.1.7. Бүлек компетенциясе өлкәсенә караган координация, консультатив органнар, иҗтимагый советлар, эксперт төркемнәре, вакытлы иҗат коллективлары һәм башка шуңа охшаш структуралар булдырырга һәм аларның эшендә катнашырга;

4.1.8. Бүлек вәкаләтләрен үтәү өчен кирәк булган өлешендә кирәкле экспертизалар һәм бәяләмәләр, шулай ук мәдәни мирас объектларына карата фәнни тикшеренүләр оештыруда һәм үткәрүдә катнашырга;

4.1.9. мәдәният өлкәсендәге оешмалардан (аларның оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә) аларның функцияләрен үтәүгә бәйле документларны, шулай ук Бүлек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мәгълүматларны соратырга һәм алырга;

4.1.10. мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшлеклеләрен билгеләнгән тәртиптә дәүләт бүләкләренә, премияләргә һәм мактаулы исемнәргә тәкъдим итү, театрларга һәм сәнгать коллективларына, аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, тиешле исемнәр бирү турында үтенечнамә бирергә (юлларга);

4.1.11. ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан гамәлгә куючы биремнәренең үтәлешен, муниципаль мөлкәтне биләүнең, аннан файдалануның һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә мөлкәтнең билгеләнеше һәм сакланышы буенча файдалануны контрольдә тотарга, оператив идарә хокукында учреждениеләргә беркетелгән артык, файдаланылмый торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне алу буенча чаралар күрергә, мәдәни мирас объектларын саклау һәм саклап калу өлкәсендәге, китапханә һәм музей эше өлкәсендәге, мәдәният өлкәсендәге театр-тамаша оешмалары һәм башка оешмалар эшчәнлегендәге, шул исәптән сәнгати (һөнәри) белем бирү, һөнәри сәнгать, үзешчән һәм башка сәнгать эшчәнлеге өлкәсендәге законнарны үтәүгә үзидарәлек контролен гамәлгә ашырырга;

4.1.12. ведомство карамагындагы мәдәният оешмаларын үзгәртеп кору, бетерү турында тәкъдимнәр кертергә;

4.1.13. дәүләт идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм башка оешмаларга гарызнамәләр юлларга һәм Бүлеккә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен кирәкле икътисади, статистик, хокукый һәм башка мәгълүматны түләүсез алырга;

4.1.14. мәдәният өлкәсендә конкурслар, фестивальләр, күргәзмәләр, күргәзмә-сатулар, симпозиумнар, конференцияләр, семинарлар, концертлар, китапханә (китаплар) алмашу һәм башка чаралар оештырырга һәм уздырырга;

4.1.15. үз профиле буенча (буклетлар, журналлар, газеталар, методик кулланмалар, ноталар, билетлар, китаплар, афишалар һ. б.) бастыру (нәшрият)

эшчәнлеген оештырырга;

4.1.16. үз компетенциясе чикләрендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең мәдәният хезмәткәрләре аттестациясен оештырырга;

4.2. муниципаль район, муниципаль район Советы, район Башкарма комитеты билгели торган башка функцияләрне гамәлгә ашырырга.

4.3. Бүлек бурычлы (тиеш):

4.3.1. үз компетенциясе кысаларында муниципаль мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итәргә, муниципаль район Башлыгы, муниципаль район Советы, Башкарма комитет җитәкчесе йөкләмәләрен (кушканнарны) вакытында үтәргә;

4.3.2. билгеләнгән срокларда үз эшчәнлеге турында муниципаль район Башлыгына, муниципаль район Советына, район Башкарма комитеты җитәкчесенә хисап тапшырырга.

## 5. Бүлек мөлкәте һәм финанслары

5.1. Бүлек мөлкәте муниципаль районның муниципаль милке булып тора һәм бүлеккә оператив идарә хокукында беркетелә.

5.2. Беркетелгән мөлкәтнең составы, аның бәясен һәм биләү, файдалану һәм эш итү шартларын бәяләү ул мөлкәтне беркетү турындагы шартнамә белән, оператив идарә хокукында һәм гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

5.3. Бүлекнең мөлкәтен һәм финанс ресурсларын формалаштыру чыганаклары түбәндәгеләр:

- бюджет һәм бюджеттан тыш акчалар;
- оператив идарәгә тапшырылган муниципаль мөлкәт;
- башка дәрәҗәдәге бюджетлардан капиталь кертемнәр һәм дотацияләр;
- түләүсез хәйрия кертемнәре, оешмалар, учреждениеләр, гражданнар иганәләре;
- Россия Федерациясе законнары нигезендә башка чыганаклар.

5.4. Оператив идарәгә тапшырылган мөлкәт арендага бирелә яисә законнарда каралган башка хокукта беркетелә, бары тик Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты рөхсәте белән генә.

5.5. Баланста торучы мөлкәт белән оператив идарә итүне гамәлгә ашырганда Бүлек бурычлы:

- оператив идарә хокукында аңа беркетелгән мөлкәтне нәтиҗәле файдаланырга, аның сакланышын һәм максатчан файдалануны тәэмин итәргә;
- оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәтнең техник торышы (хәле) начарлануга юл куймаска; бу таләп эксплуатация барышында әлеге мөлкәтнең норматив тузуына бәйле начараюына кагылмый;
- Бүлеккә беркетелгән мөлкәтне капиталь һәм агымдагы ремонтлауны тормышка ашырырга.

5.6. Бүлеккә оператив идарәгә беркетелгән мөлкәт тулысынча да, өлешчә дә түбәндәге очракларда алынырга мөмкин:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә бетерү һәм үзгәртеп кору турында карар кабул ителгәндә.

## 6. Бүлекнең структурасы

6.1. Бүлек структурасына керә:

- Бүлек Башлыгы;
- башлык урынбасары;
- финанс-хуҗалык бүлеге.

## 7. Бүлек эшчәнлеге белән җитәкчелек итү

7.1. Бүлекне Башлык җитәкли.

7.2. Башлыкны вазыйфага билгеләү һәм вазыйфасыннан азат итү, конкурс нәтиҗәләрен исәпкә алып, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.3. Бүлек Башлыгы, бүлек Башлыгы урынбасары Башкарма комитет органының вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләре булып тора.

7.4. Бүлек Башлыгы:

7.4.1.Бүлеккә бер генә кеше идарәсе нигезендә җитәкчелек итә, район Башкарма комитеты җитәкчесе каравына чыгымнар сметасын, Бүлек структурасын һәм штат расписаниесен әзерли һәм тапшыра, хезмәт законнары нигезендә Бүлек хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә, Бүлек хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслый;

7.4.2. Бүлек эшчәнлеге өчен бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренең эшчәнлеген координацияли;

7.4.3. Бүлек исеменнән ышанычнамәдән башка эшли, аны барлык предприятиеләрдә, оешмаларда, оешмаларда, судларда тәкъдим итә;

7.4.4. Бүлек хезмәткәрләренә кызыксындыру (мактау, бүләкләү) чараларын куллана һәм гамәлдәге законнар нигезендә дисциплинар җәза билгели;

7.4.5. Бүлек мөлкәте, финанс чаралары белән эш итә, счетларны ача һәм яба, алар буенча операцияләр башкара;

7.4.6. Бүлектә хезмәт, финанс һәм хисап дисциплинасы үтәлешен тәэмин итә;

7.4.7. ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен эшкә ала һәм эштән азат итә, аларга карата хезмәт законнары нигезендә дисциплинар җәза һәм кызыксындыру (бүләкләү) чараларын куллана;

7.4.8. үзенә йөкләнгән бурычларны тиешенчә гамәлгә ашыру өчен башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7.5. Бүлек башлыгы урынбасары һәм белгечләре үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны расланган вазыйфаи инструкцияләр нигезендә башкаралар.

## 8. Мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм җайга салу

8.1. Мәнфәгатьләр низагы дигәндә вазыйфа биләүче затның мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү бурычын күздә тоткан шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яисә читләтеп) булган вазгыять аңлашыла, ул аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) тиешенчә, объектив һәм гадел башкаруына йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин.

8.2. Шәхси кызыксыну дигәндә акча, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, мөлкәти характердагы хезмәтләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яисә вазыйфаи зат һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта торучы яки әшнә булган затлар (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир белән хатынның туганнары, ата-аналары, ир белән хатынның балалары һәм балаларының балалары), вазыйфаи зат һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта торучы яисә әшнәлектә булган затлар мөлкәти, корпоратив яисә башка якын мөнәсәбәтләргә бәйле булган гражданнар яисә оешмалар тарафыннан нинди дә булса файда (өстенлекләр) алу мөмкинлеге аңлашыла (алга таба – урындагы затның шәхси кызыксынуы белән бәйле затлар).

8.3. Бүлек башлыгы Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары нигезендә мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр низагын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш. Бүлек башлыгы эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) хезмәт бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә бурычлы. Хәбәр итү тәртибе Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

## 9. Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү, Бүлек эшчәнлеген туктату

9.1. Бүлекне үзгәртеп кору һәм бетерү, нигезләмәгә үзгәрешләр кертү, нигезләмәне яңа редакциядә раслау муниципаль район Советы карары буенча яки башка җирле үзидарә органы тарафыннан РФ законнарында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9.2. Бүлекне үзгәртеп кору Бүлекнең хокук һәм бурычларын аның хокук варисына күчүгә китерә.

9.3. Бүлекне бетергән очракта, муниципаль район Советы йә аның турыдан-туры вәкаләтләре буенча районның башка җирле үзидарә органы ликвидация комиссиясен билгели, ул раслауга ликвидация балансын тәкъдим итә.

9.4. Әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, бүлекнең акча средстволары һәм кредиторлар белән исәп-хисап ясаганнан соң калган башка мөлкәте Бүлек милекчесенә тапшырыла.